КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 8 февраль г.Казань № 83

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2011 ел, 10 февраль, 83 нче; 2015 ел, 16 февраль, 95 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга (карарга теркәләләр):

М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәне;

М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты турындагы нигезләмәне;

М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составын.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

3 пунктта «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты тарафыннан» сүзләрен «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әсәрләрне һәм эшләрне М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алу өчен тәкъдим итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма

органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шул исәптән Татарстан Республикасының иҗади берлекләре, шулай ук фәнни оешмалар, мәдәният оешмалары, югары белем бирүче мәгариф оешмалары тарафыннан башкарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим ителгән зат вафат булган очракта, премияне үлгәннән соң бирү рөхсәт ителә. Үлгәннән соң бүләкләнгән яки вафат булган лауреатның дипломы һәм мактаулы билгесе аның гаиләсенә истәлек буларак тапшырыла, ә акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитетында авторлык эшләрен һәм материалларны саклау срогы – бер календарь ел.;

8 пунктның икенче абзацында «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты» сүзләрен «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү турында карар М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү буенча комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты турында»1997 ел, 27 февраль, 175 нче карары белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты турындагы нигезләмә нигезендә кабул ителә. Кабул ителгән карар беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раславына тапшырыла.»;

11 пунктта «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитетын» сүзләрен «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитетын» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты» сүзләрен «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирүгә тәкъдим итү буенча барлык материаллар түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420021, Казан шәһәре, Г. Тукай урамы, 58 йорт, 302 офис, элемтә өчен телефоннар: (843) 231-81-29, (843) 231-81-19, e-mail: Molodezh.Centr@tatar.ru.»;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты турында нигезләмә»;

1 пунктта «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты» сүзләрен «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Все материалы по представлению на соискание Республиканской премии им.М.Джалиля направляются по адресу: 420021, г.Казань, ул.Г.Тукая, д.58, офис 302,

контактные телефоны: (843) 231-81-29, (843) 231-81-19, e-mail: Molodezh.Centr@tatar.ru.»;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составын раслау турында» 2011 ел, 10 февраль, 83 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составын раслау турында» 2011 ел, 10 февраль, 83 нче карары белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 141 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 16 февраль, 95 нче карарның өченче – унберенче абзацлары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1997 ел, 27 февраль, 175 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 е, 8 февраль, 83 нче
карары редакциясендә)

**М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты**

**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры – Комитет рәисе |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы, Комитет рәисе урынбасары |

Комитет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Айтуганова Миләүшә Ләбиб кызы | «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Асадуллина Алсу Мөниб кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Әхиярова Резеда Зәки кызы | Татарстан Республикасының Композиторлар берлеге рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Беляков Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Бикчәнтәев Фәрид Рәфкать улы | Россия Федерациясенең Театр эшлеклеләре берлеге бүлеге рәисе - Татарстан Республикасының театр эшлеклеләре берлеге рәисе, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бикчәнтәева Ләлә Дмитриевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе рәисе урынбасары, «Достижения молодых» Казан үзәге» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиев Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Волконадский Михаил Александрович | К. Ю. Хабенскийның «АРТХА» арт-резиденциясе генераль директоры, режиссеры, «SDVIG " Казан камера театрының генераль продюсеры (килешү буенча) |
| Галимова Лилия Камил кызы | Татарстан Республикасы Президенты Матбугат хезмәте җитәкчесе урынбасары – Казан Кремленең рәсми вәкиле (килешү буенча) |
| Гыймаев Зөфәр Фаат улы | Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Ратникова Римма Атлас кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабирова Гөлнара Ильяс кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе әгъзасы, "Шәһри Казан" газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Салихов Данил Хәбибрахман улыч | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары |
| Таюрский Дмитрий Альбертович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең белем бирү эшчәнлеге буенча проректоры (килешү буенча) |
| Тормасов Александр Геннадьевич | «Иннополис университеты» коммерциягә карамаган автоном югары белем бирү оешмасы ректоры (килешү |

| | |
|---|---|
| | буенча) |
| Туманов Дмитрий Александрович | «Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Шихобалов Валентин Викторович | «Татарстан Республикасының Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча). |